КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 август г.Казань № 658

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иннополис шәһәрен үстерү фонды» коммерциягә карамаган автоном оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 6 апрель, 217 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иннополис шәһәрен үстерү фонды» коммерциягә карамаган автоном оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 6 апрель, 217 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 18 ноябрь, 884 нче; 2018 ел, 22 март, 165 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Иннополис шәһәрен үстерү фонды» коммерциячел булмаган автоном оешмасына субсидия бирү тәртибенең 3 пунктында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин